Республика Татарстан
СОВЕТ САБИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422060, Республика Татарстан, Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы, ул. Школьная, 31а
тел. 2-30-32, 2-31-35
Факс 8(84362) 2-32-35

e-mail: sab.sab@tatar.ru

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
САБА ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.б., Мәктәп урамы, 31а йорт
тел. 2-30-32, 2-31-35
Факс 8(84362) 2-32-35

РЕШЕНИЕ КАРАР

21 март 2019 ел № 9

**Биналарга, корылмаларга, бүлмәләргә якын тирәдә алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган урыннар турында**

1995 нче елның 22 нче ноябрендә кабул ителгән 171 нче номерлы «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләт тарафыннан тәртипкә салу турында» Федераль законның 16 нчы маддәсе нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 нче елның 27 нче декабрендә кабул ителгән 1425 нче номерлы «Алкогольле продукцияне ваклап сатарга ярамый торган гражданнарның күпләп җыелу урыннарын һәм югары дәрәҗәдәге куркыныч чыганаклары урнашу урыннарын Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләү, шулай ук алкогольле продукцияне ваклап сатарга ярамый торган кайбер оешмалар һәм объектлар янындагы чикләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү турында» карары нигезендә, алкогольле продукцияне ваклап сату һәм алкогольле продукцияне ваклап сату урыннары чикләрен билгеләү буенча вәкаләтләрне тапшыру турында төзелгән килешү нигезендә, иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләрен исәпкә алып,Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 1995 нче елның 22 нче ноябрендә кабул ителгән 171 номерлы «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләт тарафынннан тәртипкә салу һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү турында» Федераль законның 16 нчы статьясындагы 2 нче пунктының 10 нчы пунктчасында күрсәтелгән биналарга, корылмаларга, бүлмәләргә якын булган территориядә алкогольле продукцияне ваклап сату 10 метр радиуста рөхсәт ителми.
2. Якын булган территория чикләрен исәпләү өчен өстәмә территория исәпләү тәртибе отсчет нокталарыннан чыгып радиус буенча билгеләнә дип билгеләргә:
а) аерымланган территорияләр булган очракта - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 нче елның 27 нче декабрендә кабул ителгән 1425 нче номерлы «Алкогольле продукцияне ваклап сатарга ярамый торган гражданнарның күпләп җыелу урыннарын һәм югары дәрәҗәдәге куркыныч чыганаклары урнашу урыннарын Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләү, шулай ук алкогольле продукцияне ваклап сатарга ярамый торган кайбер оешмалар һәм объектлар янындагы чикләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү

турында" карары белән расланган Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмалар һәм объектлар чикләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү кагыйдәләренең (алга таба – кагыйдәләр буенча) 2 нче пунктында күрсәтелгән аерымланган территорияләргә йомыш белән килүчеләр өчен керү юлыннан;
б) кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгән оешмалар һәм (яки) объектлар урнашкан бинага (төзелешкә, корылмага) аерымланган территория булмаганда.
3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр башкарма комитетына әлеге карар нигезендә күрсәтелгән Кагыйдәләрнең 2 нче пунктында күрсәтелгән һәр оешма һәм (яки) объект өчен якын булган территорияләрнең чикләре схемасын эшләргә һәм расларга.
4. Гражданнар күпләп җыела торган урыннарда районкүләм чаралар үткәрү вакытында алкогольле продукцияне ваклап сату Саба шәһәр башкарма комитетының аерым карары белән регламентлана дип билгеләргә.
5. Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Саба районындагы территориаль бүлегенә, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Арча территориаль органына, Саба районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча Эчке эшләр бүлегенә федераль законнарның үтәлешен һәм әлеге карарның үтәлешен тикшереп торырга тәкъдим итәргә.
6. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһә җирлеге Советының 2017 нче елның 29 нчы ноябрендә кабул ителгән 38 нче номерлы «Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган биналарга, корылмаларга, бүлмәләргә якын урыннар турында турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.
7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/rus/saba, җирлекнең информацион стендларында бастырып чыгарырга.
8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Саба шәһәр җирлеге
башлыгы урынбасары Р.М.Хәсәнов